**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 8 октябрь № 728

г. Казань

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгын Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техника-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасы белән идарә итү вәкаләтләрен башкару йөкләнгән орган итеп билгеләү турында

«Россия Федерациясендә махсус икътисадый зоналар турында» 2005 ел, 22 июль, ФЗ-116 нчы Федераль закон, Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техника-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасы белән идарә итү буенча аерым вәкаләтләрне бирү турында» 2016 ел, 18 апрель, 249 нчы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына махсус икътисадый зона белән идарә итү вәкаләтләрен бирү турындагы 2016 елның 5 сентябрендәге С-582-АЦ/Д14 нче килешү нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгын Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техника-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасы белән идарә итү вәкаләтләрен (проект документларына экспертиза һәм инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә экспертиза үткәрүне тәэмин итү вәкаләтеннән тыш) башкару йөкләнгән, шул исәптән түбәндәгеләргә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы итеп билгеләргә:

махсус икътисадый зона резидентлары реестрын алып бару;

махсус икътисадый зона резидентлары таләбе яки мәнфәгатьле затлар соратуы буенча махсус икътисадый зона резидентлары реестрыннан өземтә бирү;

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 2009 ел, 16 март, 82 нче боерыгы белән расланган тәртиптә сәнәгать-җитештерү, техника-гамәлгә кертү, туристлык-рекреация эшчәнлеген яки портлы махсус икътисадый зонада эшчәнлекне гамәлгә ашыру турындагы килешүләрне махсус икътисадый зона резидентының үтәвен тикшерүдә тотуны тормышка ашыру;

«Россия Федерациясендә махсус икътисадый зоналар турында» Федераль закон белән расланган тәртиптә техника-гамәлгә кертү яки сәнәгать-җитештерү эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында килешүләр төзү;

махсус икътисадый зона чикләрендә территорияне планлаштыру документларын әзерләү буенча һәм федераль бюджет, Россия Федерациясе субъекты бюджеты, җирле бюджет акчасы исәбеннән, Россия Федерациясе законнарында башкасы каралган булмаса, әлеге зонаның инженерлык, транспорт, социаль, инновация һәм башка инфраструктураларын төзү буенча дәүләт заказчысы функцияләрен башкару.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков